ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 декабрь, 2020 ел № 4/3

Җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, Шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислары мирас хокукыннан баш тарткан очракта, варислары булмаган яки мирас ачылган көннән соң бер ел дәвамында мирас алмаган очракта, вафат булган яки вафат булган дип игълан ителгән физик затларның хасил булу датасыннан өч елдан артык түләнмәгән салымнары, пенялары һәм штрафлары булу;

2) оешмалар, шәхси эшмәкәрләр яки физик затларның 2017 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнары, пенялары һәм штрафлары булу;

3) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктларында каралган нигездә, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкару производствосын тәмамлау турында карар чыгаруга бәйле рәвештә салым органнары тарафыннан түләттерү мөмкин булмаган очракта, хасил булган датадан алып өч елдан артык җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар булу.

2. Җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуны раслаучы документлар исемлеген кушамтада каралганча расларга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
4/3 Карарына кушымта
29 декабрь, 2020 ел

Җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслаучы документлар исемлеге

1. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

1) физик затның теркәлү урыны буенча салым органыннан түләнмәгән салым, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар күрсәтелгән белешмә;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясы 3 пункты нигезендә салым органыннан физик затларның гражданлык хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан физик затның вафат булу фактын теркәү турында белешмәләр;

3) варисларның мирас хокукыннан баш тартуын, варислар булмауны яки мирас ачылганнан соң бер ел дәвамында мирасны кабул итмәүне раслаучы документлар.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

1) оешманы, шәхси эшмәкәрне, физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органынннан түләнмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммасы турында белешмә;

2) салымны гамәлдән чыгару нигезе булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, номеры, датасы).

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

1) оешманы, шәхси эшмәкәрне, физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органыннан түләнмәгән салым, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммасы турында белешмә;

2) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктларында каралган нигездә түләтүчегә башкарма документны кире кайтару белән бәйле рәвештә башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд приставы-башкаручы карары.